# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында" 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 1 (1); 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ статья өстәргә:

"$3^1$ статья. **Җәмәгать судьясының җәмәгать судьясы аппараты эшен оештыру вәкаләтләре**

Җәмәгать судьясы җәмәгать судьясы аппараты эшен оештыру буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) суд эшләрен алып бару буенча җәмәгать судьясы аппараты эшен оештыра;

2) җәмәгать судьясы аппараты хезмәткәрләре арасында вазыйфаи бурычларны бүлә;

3) судларның эчке тәртибенең Россия Федерациясенең Судьялар советы тарафыннан раслана торган үрнәк кагыйдәләре нигезендә эчке тәртип кагыйдәләрен билгели;

4) җәмәгать судьясы аппараты хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын башкаруларын тикшереп тора, җәмәгать судьясы аппараты хезмәткәрләрен бүләкләү йә аларны дисциплинар җаваплылыкка тарту турында тәкъдимнәр кертә;

5) законнар нигезендә статистик хисаплылык төзүне тикшереп тора;

6) җәмәгать судьясы аппаратында алып барыла торган нарядлар номенклатурасын раслый;

7) суд участогы документларын саклауны, сайлап алуны һәм архивка тапшыруны, саклау срогы чыккан эшләрне һәм материалларны ел саен сайлап алуны һәм юк итүне оештыра;

8) әйберләр рәвешендәге дәлилләрне исәпкә алу журналын алып баруның дөреслеген, әйберләр рәвешендәге дәлилләрнең фактта булуына язмаларның туры килүен, әйберләр рәвешендәге дәлилләр өлешендә хөкемнәрнең, хәл итүләрнең, билгеләмәләрнең, карарларның үз вакытында башкарылуын кимендә кварталга бер тапкыр тикшерә;

9) суд эшләрен, материалларын, документларын компетентлы органнар гарызнамәләре буенча бирүгә яисә җибәрүгә рөхсәт бирә;

10) квалификация арттыру эшен оештыра;

11) җәмәгать судьясы эшчәнлеге турындагы мәгълүматны федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Интернет челтәрендә урнаштыру эшен оештыра;

12) бүтән гамәлләр башкара.";

2) 4 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4 статья. **Суд участоклары һәм җәмәгать судьясының даими булу урыны**";

б) түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

"7. Җәмәгать судьясының даими булу урыны, тиешле район суды рәисенең фикерен исәпкә алып, "Татарстан Республикасында суд участокларын төзү һәм җәмәгать судьялары урыннарын булдыру турында" 2000 елның 31 маендагы 177 номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә.";

3) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5 статья. **Җәмәгать судьясына һәм җәмәгать судьясы вазыйфасына кандидатка куела торган таләпләр**

Җәмәгать судьясына һәм җәмәгать судьясы вазыйфасына кандидатка "Россия Федерациясендә судьялар статусы турында" Россия Федерациясе Законы нигезендә судьяларга һәм судья вазыйфасына кандидатларга куела торган таләпләр "Россия Федерациясендә җәмәгать судьялары турында" Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып куела.";

4) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ һәм $5^2$ статьялар өстәргә:

"$5^1$ статья. **Җәмәгать судьясын яңадан һөнәри әзерләү**

1. Җәмәгать судьясы вазыйфасына беренче тапкыр сайланган җәмәгать судьясы яңадан һөнәри әзерлек уза.

2. Җәмәгать судьясы вазыйфасына беренче тапкыр сайланган җәмәгать судьясы, шушы чор өчен хезмәт хакы сакланып калган килеш, судьяларны һөнәри яңадан әзерләүне һәм аларның квалификациясен арттыруны гамәлгә ашыра торган югары һөнәри һәм өстәмә һөнәри белемнең мәгариф учреждениеләрендә (алга таба – мәгариф учреждениеләре) укыту һәм җәмәгать судьясында стажировка рәвешләрендә яңадан һөнәри әзерлек уза. Моңарчы судья вазыйфасын биләгән затлар яңадан һөнәри әзерлек узудан азат ителә.

3. Җәмәгать судьясы вазыйфасына беренче тапкыр сайланган җәмәгать судьясын яңадан һөнәри әзерләү вазыйфаи бурычларны башкарудан аерылып гамәлгә ашырыла.

4. Җәмәгать судьясы вазыйфасына беренче тапкыр сайланган җәмәгать судьясын яңадан һөнәри әзерләүнең гомуми озынлыгы алты айдан артык була алмый. Укыту рәвешендәге яңадан һөнәри әзерләүнең конкрет сроклары юстиция өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан тиешле шартнамә төзелгән мәгариф учреждениесенең уку-укыту программалары (планнары) нигезендә билгеләнә.

5. Укыту рәвешендәге яңадан һөнәри әзерлек узу турындагы документның күчермәсе җәмәгать судьясы вазыйфасына беренче тапкыр сайланган җәмәгать судьясы тарафыннан Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсенең кадрлар хезмәтенә тапшырыла.

6. Укыту рәвешендәге яңадан һөнәри әзерлек тәмамланганнан соң җәмәгать судьясы вазыйфасына беренче тапкыр сайланган җәмәгать судьясы юстиция өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органының күрсәтмә акты нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә суд эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган, стажировка җитәкчесе булган җәмәгать судьясында стажировка рәвешендә яңадан һөнәри әзерлек узарга җибәрелә.

7. Турыдан-туры судья вазыйфасында кимендә өч ел хезмәт стажы булган һәм җәмәгать судьясы вазыйфасына беренче тапкыр сайланган җәмәгать судьясының суд участогы урнашкан суд районы территориясендә суд эшчәнлеген гамәлгә ашыручы җәмәгать судьясы стажировка җитәкчесе була ала.

8. Суд районында бер генә суд участогы булган очракта, җәмәгать судьясы вазыйфасына беренче тапкыр сайланган җәмәгать судьясы якындагы суд районының суд участогына кимендә өч ел хезмәт стажы булган җәмәгать судьясына стажировкага җибәрелә.

9. Җәмәгать судьясы вазыйфасына беренче тапкыр сайланган җәмәгать судьясының стажировка рәвешендә яңадан һөнәри әзерлек узу срогы бер ай була.

## $5^2$ статья. **Җәмәгать судьясы квалификациясен арттыру**

1. Җәмәгать судьясы квалификациясен арттыру кирәк саен, әмма кимендә өч елга бер тапкыр, шушы чор өчен хезмәт хакы сакланып калган килеш, мәгариф учреждениеләрендә укыту рәвешләрендә гамәлгә ашырыла.

2. Җәмәгать судьясы квалификациясен арттыру вазыйфаи бурычларны башкарудан аерылып гамәлгә ашырыла.

3. Җәмәгать судьясы квалификациясен укыту рәвешендә арттыруны тиешле мәгариф учреждениесенең уку-укыту программалары (планнары) буенча уза.

4. Җәмәгать судьясының квалификациясен укыту рәвешендә арттыру срогы юстиция өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан тиешле шартнамә төзелгән мәгариф учреждениесенең уку-укыту программалары (планнары) нигезендә билгеләнә.

5. Квалификация арттыру тәмамланганнан соң җәмәгать судьясы билгеләнгән үрнәктәге документ ала. Квалификация арттыруны узу турындагы документның күчермәсе җәмәгать судьясы тарафыннан Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсенең кадрлар хезмәтенә тапшырыла.

6. Җәмәгать судьясының квалификациясен стажировка рәвешендә арттыру юстиция өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органының күрсәтмә акты нигезендә Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсе белән килештереп гамәлгә ашырыла.

7. Җәмәгать судьясының квалификациясен стажировка рәвешендә арттыру срогы бер ай була.

8. Җәмәгать судьяларының квалификацияләрен арттыру Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән гамәлгә ашырыла.";

5) 8 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару "Россия Федерациясендә судьялар статусы турында" Россия Федерациясе Законының $7^1$ статьясында каралган тәртиптә отставкадагы судьяга йөкләнергә мөмкин.";

6) 9 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

"5. Җәмәгать судьясы аппараты турындагы нигезләмә юстиция өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан әзерләнә һәм раслана.";

7) 9 статьяның 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

"4. Җәмәгать судьясы аппараты хезмәткәрләрен эшкә кабул итү һәм эштән азат итү юстиция өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

8) 10 статьяда:

3 пунктта "Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына" сүзләрен "юстиция өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына" сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта "Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы" сүзләрен "юстиция өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. "Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында" 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законының (әлеге Закон редакциясендә) $5^1$ һәм $5^2$ статьяларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү җәмәгать судьялары эшчәнлеген матди-техник тәэмин итүгә каралган чаралар чикләрендә Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 42-ТРЗ